Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№2 (34)

Ноябрь-декабрь, 2019 нчы ел

Бу санда

*Гимназия сулышы* 1

*Минем яраткан шөгылем* 2-3

*Гимназия яшьләре мәйданчыгы* 4




**Кадерле дусларыбыз, Яңа 2020 ел яңа шатлыклар, матур мизгелләр, ак бәхетләр алып килсен!**

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### ТОРМЫШ ДӘРЕСЛӘРЕ



“Тормыш дәресләре” проекты кысаларында 9-11 нче сыйныф укучылары мәгариф идарәсе җитәкчесе Р.Т.Демидов белән очрашып, “уңышлы” булу серләре белән уртаклаштылар. Рафаэль Тимофеевич лидерлык сыйфатларын балачактан тәрбияләү кирәклеген аңлатты, укучыларның күпсанлы сорауларына җавап бирде.

### КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР, БӘЙГЕЛӘР





«Без – сәләтле буын!” регионара фәнни-тикшеренү конференциясендә гимназия укучылары бик яхшы нәтиҗәләр күрсәтте. Инглиз теле секциясендә Кашапов Данияр (5а) - өченче урын, Бурганова Рената, Галиуллина Рания (9а) - икенче урын; әйләнә-тирә дөнья секциясендә Бариев Ислам (1б) – 1 нче урын, Галимова Айназ (3б) - 3 нче урын, Бурганова Карина (4а) – 2 нче урын яуладылар. Бариева Илина (7б) биология секциясе җиңүчесе булды. 9 нчы а сыйныфы укучысы Нассер Мәрьям математика буенча 3 нче урын, 7 нче а сыйныфы укучысы Бәдертдинова Әдилә рус теле секциясендә 1 нче урын яулады.

Башлангыч сыйныфлар арасында “Бәхетле балачак” сәнгатьле сөйләм бәйгесе узды. Гимназия укучылары югары күрсәткечләргә ирештеләр.

### СПОРТТА ДА КӨЧЛЕ БЕЗ!





## МИНЕМ ЯРАТКАН ШӨГЫЛЕМ

**Хисамова Язилә:**

***Безнең төп эшебез – уку. Шулай булса да, барыбыз да үзебезне укудан тыш башка өлкәләрдә дә сынап карыйбыз. Кемдер спортны, кемдер музыка дөньясын, кемдер шигъриятне үз итә, бию, тегү, чигү, рәсем ясау, ашарга пешерү осталары бар. Буш вакытта файдалы эшләр белән шөгыльләнергә бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Сәнгать мәктәбе, спорт мәктәбе, гимназиядәге түгәрәкләр – барысы да безнең мөмкинлекләрне үстерү, сәләтләребезне ачу өчен бик кулай. Яраткан шөгыле булган кешенең тәртипсезлекләр эшләргә вакыты калмый, минемчә.***

***Безнең яшьтәшләребез буш вакытларын ничек уздыралар? Аларның яраткан шөгыльләре бармы? Әйдәгез, танышыйк.***

**Биккинина Наилә:**

Минем яраткан шөгылем – бию. Мин инде 6 ел бик җитди шөгыльләнәм. Киләчәктә бик шәп биюче булырга хыялланам.

**Хәйдәров Ришат:**

Мин футбол уйнарга яратам. Без бик күп ярышларда катнашабыз. Яр Чаллы, Әлмәт, Бөгелмә, Казанда да уйнадык. Әлбәттә, ярыш булгач, җиңүләр дә, җиңелүләр дә була. Команда белән бергә бөтен авырлыкларны җиңәргә өйрәнәсең – бу бик шәп! Мин футболга гомер буе тугры калырмын дип уйлыйм.



**Каюмова Ләйлә:**

Мин рәсем ясарга яратам. Күбрәк хайваннар ясыйм, чөнки үзем дә хайваннарны яратам.

**Шәйсолтанов Раил:**

Мин сәнгать мәктәбендә Ибраһимов Илшат абый җитәкчелегендә рәсем ясау белән профессиональ шөгыльләнәм. Киләчәктә бу шөгылемне дәвам итеп, архитектура юнәлешендә эшләргә телим.

**Нургалиева Алинә:**

Мин бисер белән төрле сувенирлар ясарга яратам, 5 яшьтән гимнастика белән шөгыльләнәм.

**Мирзаянов Гадел:**

Мин тынлы уен коралларын үз иттем. Башта альтта уйный идем. Төрле инструментларда уйнап, үземне сынап карадым. Аеруча трубада уйнарга яратам. Миңа аның тавышы ошый. Хәзер трубада яңа көйләр өйрәнәм.

**Ибраһимова Регина:**

Мин йөзү спорты белән шөгыльләнәм. Брасс, кроль ысулы белән йөзү ошый. Йөзү – бик файдалы спорт. Ул мускулларны ныгыта, тын юлларын ача. Мин йөзү буенча бик күп ярышларда катнаштым, муниципаль, республика ярышларында алган медальләрем шактый. Һәр кешегә бассейнга йөрергә тәкъдим итәм.

**Ильясов Шамил:**

Мин велоспорт яратам, үзем дә җәен-кышын велосипедта йөрим.

**Хатипова Ралина:**

Мин соңгы вакытта билбау көрәше белән шөгыльләнә башладым. Бу спорт төрен ир-атлар да, хатын-кызлар да үз итә. Ул физик ныклык, характер формалаштырырга ярдәм итә, кагыйдәләр буенча эш йөртергә өйрәтә. Инде беренче уңышларым да бар. Билбау көрәше буенча өченче урын һәм медаль алдым. Бу уңыш мине яңа җиңүләргә рухландырды.

**Габидуллина Азалия:**

Мин дә рәсем ясарга яратам. Табигатьнең иң матур мизгелләрен сурәткә төшерәм. Язның беренче чәчәге умырзаяны, болыннарның яшелләнгән вакытын, агачларның бөреләнүен, көзге табигатьнең могҗизалы матур төсләрен картинада чагылдырырга яратам. Кышның ап-ак карлары, суыкның тәрәзәгә ясаган бизәкләре, кар бөртекләренең күбәләктәй уйнаулары – болар берсе дә мине битараф калдырмый. Рәсем ясый белү тормышта да бик кирәк дип саныйм.



**Хаҗиев Алмаз:**

Мин кышны сагынып көтәм. Минем чаңгыларым да кыш җитүен көтеп яталар. Узган ел миңа яңа чаңгылар алдылар, шуннан бирле мин чаңгы спортын үз иттем. Төрле ярышларда рәхәтләнеп катнашам.

**Хәйруллина Алинә:**

Мине кечкенәдән музыка дөньясы үзенә тарта. Минем әбиләрем дә, әнием дә яшь вакытта җырлаган, шуңа күрә музыкага мәхәббәт безнең нәселдән килә дип уйлыйм. Мин ноталар өйрәнәм, яңа җырларны нотага карап, төгәл авазлар белән,

# МИНЕМ ЯРАТКАН ШӨГЫЛЕМ

матур итеп җырларга тырышам. Сәнгать дөньясының чиксез серләрен ачарга телим.

***Гомәрова Эльмира:*** Мин кул эшләре ясарга, рәсем ясарга яратам. Әлмәт шәһәрендә яшәп иҗат итүче абыем - рәссам Гомәров Ришат - минем ясаган натюрмортларны, табигать күренешләрен ошатты, үзенең киңәшләрен бирде. Үз кулларым белән ясаган матур әйберләрне туганнарга, дусларыма бүләк итәм. Аларның шатлануын күреп, минем күңелләрем нечкәрә.



***Гайсин Ранис:***

Миңа физкультура белән шөгыльләнү бик ошый: йөзүне үз итәм. Шулай да, физик яктан гына түгел, акыл ягыннан да үзеңне үстерергә кирәк. Балалар бакчасыннан ук мине шахмат фигуралары үзенә тартты. Зөлфәт бабам һәм әтием белән буш вакытларда шахмат уйный башладым. Шахмат – бик мавыктыргыч, шул ук вакытта зиһенгә файдалы уен. Ул алдагы адымнарны күзалларга өйрәтә, логика сәләтен үстерә.

***Хөсәенова Адилә:***

Соңгы вакытта мин аш-су пешерү серләренә өйрәнә башладым. Баштарак әни белән бергә пешерә идек, хәзер инде үзем генә дә бик күп тәмле ризыклар ясарга өйрәндем. Кекслар хәттә әникенә караганда да яхшырак чыга башлады. Пешергән ризыкларымны мактый-мактый ашыйлар, әтиемнең мактавын ишетүе аеруча рәхәт.

***Харисов Айзат:***

Минем иң яраткан шөгылем – балык тоту. Кечкенә вакыттан ук мине әти кармак белән балык тотарга өйрәтте. Башта кечкенә кармаклар бирә иде, хәзер инде зур кармаклар белән йөрим. Әти миңа балык тотуның барлык нечкәлекләрен өйрәтә. Карп, табан, алабуга балыклары тотканым бар. Быел зур чуртан тоттым, судан үзем тартып чыгардым. Суда боз каткач, тагын балыкка йөри башлыйбыз. Боз өстендә кышки балык тотуның рәхәтен сүз белән генә аңлатып булмый. Без аңа әти белән алдан ук әзерләнеп куябыз. Махсус кармаклар, җылы киемнәребез инде әзер. Әле быел бер тапкыр да бармадык. Мин ул көнне түземсезлек белән көтәм.

***Газетдинова Азалия һәм Адилә:***

Без бала вакыттан ук җырларга ярата идек, нинди җыр ишетсәк тә, аны отып калып, җырлап йөри идек. Хәзер сәнгать мәктәбенең вокал бүлегендә җыр белән шөгыльләнәбез. Безгә сәхнәдә чыгыш ясау бик ошый.



***Солтанова Назлыгөл:*** Бу уку елында мин үземне бөтенләй башка яктан ачтым. Гимназиядә Синара Яббарова җитәкчелегендә “Нур” исемле театр сәнгате түгәрәге эшли башлады. Башта кастинг үттек, аннары ике төркемгә бүленеп, түгәрәктә шөгыльләнә башладык. Сәхнәдә үзеңне тоту, сөйләм культурасы, мимика, хәрәкәт итү серләренә төшенә башлагач, Г.Камалның “Беренче театр” комедиясен сәхнәләштердек. Инде беренче эшебезне республика конкурсына тәкъдим итәргә дә өлгердек.



***Гомумән, укучыларыбыз буш вакытларын бушка уздырмый икән. Кемдер үзен спорт, сәнгать, мәдәният дөньясында тапкан яисә башка өлкәләрдә мавыгулары бар икән, болар барысы да мактауга лаек. Шунысы кызганыч: буш вакытта китап укучыларны гына таба алмадык.***

### ГРАНТ! ГРАНТ! ГРАНТ!

*Татарстанда 2020 нче ел - ТАССРның 100 еллыгы билгеләп үтеләчәк. Шул уңайдан гимназия күләмендә «100 «5» лем – ТАССРның 100 еллыгына бүләгем» дип аталган Грант булдырыла. Татар теле һәм әдәбияты фәннәреннән 2020 нче ел дәвамында йөз «5» ле билгесе алучы укучыларга 1000 сум күләмендә премия тапшырылачак. Бүләкләү тантаналы шартларда оештырылачак.*

*Телебезне саклау, милләтебезне үстерү максатыннан, Грант конкурсына катнашырга чакырабыз, хөрмәтле гимназия укучыларыбыз!*

## ГИМНАЗИЯ ЯШЬЛӘРЕ МӘЙДАНЧЫГЫ

### ЖЕВАЧКАНЫҢ ТУГАН КӨНЕ

***ЖЕВАЧКАның туган көне бармы? Аңа ничә яшь дип уйлыйсыз? Ничек уйлап тапканнар? Хәзер беләбез!***

1848 елның 23 сентябрендә туган ул. Һәм быел ул үзенең 171 еллыгын билгеләп узды! Моннан 171 ел элек Джон Куртис исемле кеше Америкада жевачка ясый. Шуны да белү мөһим: жевачка ашап булмый торган эластик матдәдән гыйбарәт, аңа төрле тәмнәр кушалар һәм без исебез китә-китә аларны кырылып алабыз.

Әмма жевачаның аңа кадәр үк булуы турында фикерләр бар. Ул б.э.к. 7-2 гасырларда инде кулланылган дип санала. Төньяк Еропада барган казу эшләре вакытында табыла ул.

Борынгы греклар мастика исемле агачның сумаласын чәйнәсәләр, һиндлылар якынча 1000 ел элек тешләрне чистарту өчен саподилла агачының куерган согын кулланганнар. Тора бара аның яңа вариантлы барлыкка килә. Агач сумаласы яки умарта корты балавызыннан була ул.

Джон Куртиска яңадан әйләнеп кайтык әле. 1848 елда ул нарат сумаласыннан жевачкаларны куплэп җитештерә башлый. Вакыт узу белән, аларны төрле тәмнәрдә чыгарырга тотына.Тик Куртисның сату эшләре бик алга китә алмый, чөнки сумаладагы тәмне боза торган катнашмаларны ул һич бетерә алмый.

Томас Адамс 1869 жевачкага яңа сулыш өрә. Ул аны каучуктан ясый. 1871 елда үзе уйлап тапкан махсус машинага патент ала. Шулай ук жевачканың тәмен дә яхшырта. Аның продукты бик киң тарала.

СССРда чит ил жевачкасы балалар һәм яшүсмерләр арасында бик популяр һәм шул ук вакытта алтын бәясенә тиң була. Ник дигәндә, ул безнең илдә җитештерелми, ә соңрак җитештерелгән аналогларның сыйфаты күпкә түбән бәяләнә.




***Безнең укучылар арасында жевачка ни дәрәҗәдә популяр? Бу турыда Айназ Закирова сораштыру үткәрде.***

Буфет хуҗасы Дания апа:

Буфетта жевачка сатарга рөхсәт ителми, балалар суыра торган жевачка-конфетларны яратып алалар. Бер көн эчендә якынча 120-200 конфет сатыла. Балалар баллы ярата. Жевачкаларны күбрәк укытучылар һәм югары сыйныф укучылары ала. Көчле мята тәме, арбуз, ментол тәме кушылганнарны алалар. Кайсына да булса өстенлек бирәләр дип әйтеп булмый, һәркемнең зәвыгы үзенчә.

Укучылар арасында иң популяр жвачкалар: Orbit (мята, лайм, арбуз, банан).

## ГИМНАЗИЯ УКЫТУЧЫЛАРЫ-СӘХНӘ ЙОЛДЫЗЛАРЫ
















**ТЫЛСЫМ+**

Ноябрь-декабрь, 2019 нчы ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Нассер Мәрьям

**Корректорлар:** Ханнанова Алинә

**Корреспондентлар:** Бәдретдинова Әдилә, Идиятуллина Сабина

**Дизайнер:** Шәкертҗанов Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Шәйхиев Раил

**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Тираж**: 100